ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 494 от «11» 12 2023 г.

2024 елга Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районында
халыкка торак-коммуналь
хезмәтләр күрсәтү тарифларын
раслау турында

Россия Федерациясе Торак Кодексының 156, 158 статьялары, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә эшен оештыру принциплары турындагы» 131-ФЗ номерлы Федераль Закон нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. 2024 елга торак-коммуналь хезмәтләр өчен тарифларны түбәндәгечә расларга һәм гамәлгә кертергә:

- социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен һәм гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләре өчен торак хезмәтләре тарифларын 1 нче кушымта нигезендә;

- торак урынын наемга алу өчен (социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарын найм шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен) 2 нче кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны «Нократ» («Вятка») район газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.Х.Әгъләмовка йөкләргә.

Җитәкче О.Н.Павлов

0000012110

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль
районы Башкарма комитетының
11 12 2023 ел,
№494 карарына
1 нче кушымта

**Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен һәм гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләре өчен торак хезмәтләре тарифлары**

| Хезмәт исеме | Түләү алынучы үлчәү берәмлеге | Бер төр хезмәткә алынучы түләү тарифы, 2024 елның 1 гыйнварыннан | Бер төр хезмәткә алынучы түләү тарифы 2024 елның 1 июленнән |
|---|---|---|---|
| Торак фонды белән идарә итү | **Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м.** | **2,62** | **2,62** |
| **Йорт яны территориясен җыештыру** | **Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м.** | **2,14** | **2,14** |
| **Торак биналарны ремонтлау һәм йорт яны территориясен көндәлек төзекләндерү** | **Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м.** | **2,26** | **2,26** |
| **Техник хезмәт күрсәтү һәм йорт эчендәге санитар-техник челтәрләрне ремонтлау** | **Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м.** | **1,15** | **1,15** |
| Газ белән тәэмин итү челтәренремонтлау һәм техник хезмәт күрсәтү | **Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м.** | **0,25** | **0,25** |
| **Электр энергиясе белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау һәм техник хезмәт күрсәтү** | **Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м.** | **0,99** | **0,99** |
| **гомуми файдалану урыннарын җыештыру** | **Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м.** | **2,92** | **2,92** |
| **Вентиляция каналларына хезмәт күрсәтү** | **Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м.** | **0,58** | **0,58** |

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль
районы Башкарма комитетының
11 12 2023 ел,
№ 494 карарына
2 нче кушымта

Торак урынын наемга алу өчен
(социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарын найм шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен)
тарифлар

| Күрсәтелүче хезмәтнең исеме | Түләү алынучы үлчәү берәмлеге | Бер төр хезмәткә Алынучы түләү тарифы, сумнарда, 2024 елның 1 январеннән | Бер төр хезмәткә алынучы түләү тарифы 2024 елның 1 июленнән |
|---|---|---|---|
| Торак бинаны наймга алу | Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м | 6,09 | 6,09 |